# «Мин татар кызы»

1.Мин татар кызы, мин татар кызы!
Шуңа сөенәм, шуңа шатланам!
Чибәр сеңлебез дисәләр миңа,
Мин татар шул дип, и, канатланам!

2.Татар телемне - нәфис гөлемне
Саклап яшәргә сезгә сүз бирәм!
Татарча укыйм, татарча җырлыйм,
Бик тыйнак кына елмаям, көләм.

3.Татар кызы мин - озын толымым
Чулпылар белән матурлап үрәм.
Әнием белән чәк-чәк пешерәм,
"Әллүки" көйләп кулъяулык чигәм.

**Кушымта**
Мин татар кызы, мин татар кызы
Горур милләтнең якты тамчысы.
Ана телемне өз(е)леп сөюче
Мин татар кызы, мин татар кызы!